«Дин – ул, нәсыйхәт»
силсиләсе (15)

Ниязетдин мулла
Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Мин мөселмән




# Таян Аллага



Әй бәһале, әй кадерле, әй
гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның,
һәрдәим таян син Аллага!
Йә ходай, күрсәт, диген, ошбу
җиһанда якты юл;
Ул – Рәхимле; әткәң-әнкәңнән
дә күп шәфкатьле Ул!
Саф әле күңлең синең,
һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз
сүзләр әйтеп күрмәгән.
Пакь җаның һәм пакь тәнең –
барлык вөҗүдең пакь синең:
Син фәрештә валчыгысың,
йөзләрең ап-ак синең!
Кыйл дога, ихлас белән
тезлән дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән
тугъры юл бар гаршенә!
Әй бәһале, әй кадерле, әй
гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның,
һәрдәим таян син Аллага!

(Габдуллаһ Тукай)


# Аллаһ барча нәрсәне булдыручы






Укытучы балаларга Аллаһ тәгаләнең кешеләрне, кояшны, айны, агачларны, хайваннарны... һәм барча нәрсәне дә халикъ кылганлыгы вә һәрнәрсәгә кадир булганлыгы турында аңлата. Шулай ук, аларга мәхлукатларның күктәге, җирдәге вә диңгездәге төрләрен әйтеп уза


# Авылга сәфәр






Укытучы балалар белән Аллаһның Бөек халикъ кылучы икәнлеге турында әңгәмәне дәвам итә. Аларга агачлардан җимеш, йомыркадан чебеш чыкканлыгы хакында сөйли һ.б.


# Аллаһ ризыкландыручы






Укытучы балаларга Аллаһ тәгаләнең барча мәхлукатларны да ризыкландырганы турында сөйли. Мәсәлән, кешеләрне, хайваннарны, кошларны, балыкларны, хәтта карындагы баланың ничек ризыклануы хакында аңлатып китсә дә мөмкин

# Хатын һәм песи





Мин сезгә, бер песи сәбәпле Утка кергән хатын турында сөйлим



Ничек ул алай була эти?



Бервакыт бер ач песи каты йөрәкле, явыз хатынның йортына керә, һәм бу хатын ашарга бирмәс микән дип аның янына якынлаша. Ләкин явыз вә каты йөрәкле хатын песине тотып ала да бәйләп куя. Ул аны кыйный, ашарына-эчәренә бирми һәм песи зәгыйфьләнеп үлә



Бу хатын бик тә явыз булган. Ни өчен соң песине җибәрмәгән, ул үзе ризык табыр иде?



Әйе, песине үз ризыгын үзе табыр өчен җибәрмәгәнлектән һәм газаплаганлыктан үлгәч, Аллаһ тәгалә бу хатынны Утка кертте



Мөселман хайваннарны газапламый вә рәнҗетми, чөнки Ислам дине, хәтта хайваннарга карата да мәрхәмәтлек дине




Укытучы балаларга бу хикәяттәге гыйбрәтләрне аңлатып китә. Бу хатын песине бәйләп куюып аны ашатмавы-эчертмәве сәбәпле хаталанганын, ялгышканлыгын бәян итә. Шулай ук, мөселманның хайваннарга карата мәрхәмәтле булуын, аларга ашарга-эчәргә биреп тәрбияләргә кирәклекне әйтә

# Аллаһ кешегә барча нәрсәне буйсындырды

*Әй кардәшләрем! Карагыз әле, Аллаһ тәгалә кеше өчен барча нәрсәне буйсындырды:*



*Хайваннарны..*
*Үсемлекләрне..*
*Кояшны..*
*Диңгезләрне..*
*Очакларны..*





Укытучы балаларга Аллаһ тәгалә барча нәрсәләрне дә кешегә буйсындырганын аңлата. Мәсәлән; сыердан кеше сөт, май, эремчек, катык, ит һәм башка нәрсәләр белән файда күрә. Шулай ук, ат, дөя, сарык кебек башка хайваннар да кешегә бик күп файдалар китерә. Болар һәммәсе дә Аллаһның кешегә биргән нигъмәте

# Аллаһның нигъмәтләреннән

*Хайваннарның кешегә буйсынуы, Аллаһның нигъмәтләреннән. Дөя чүллектә йөрергә яраклашкан, сыерлар әйткәнебезчә сөт-ит бирә. Мин сезгә бер хикәя сөйлим. Бу, хайваннарны тиешлечә кулланмау турында*

*Әйдә әти, сөйлә, сөйлә!*


*Көннәрнең берендә кешеләр пәйгамбәребезнең артыннан ияреп барган дөяне күрделәр. Пәйгамбәребез бакчага кереп киткәч, дөя дә аның артыннан керде һәм пәйгамбәребезнең алдына басты да, күз яшьләре белән елый башлады. Пәйгамбәребез аның муеныннан сыпырды һәм дөянең ни өчен елаганын аңлап, хуҗасын чакырырга кушты. Дөянең хуҗасы пәйгамбәр янына бик тиз рәвештә килеп тә җитте. Пәйгамбәребез аңа, дөягә аз ризык ашатуларыннан һәм күп эшләтүләреннән зарланганын әйтте. Аннары, дөягә мәрхәмәтле булуы белән үгет-нәсыйхәт кылды. Чөнки, Ислам ул кешеләргә дә, хайваннарга да мәрхәмәтлек дине*



# Ислам нигезләре



*Әйдәгез әле кардәшләрем,
Ислам нигезләрен
бергәләшеп кабатлыйк!*




*Пәйгамбәребез әйтте: "Ислам, биш нигезгә төзелгән: "Лә иләһә илләАллаһ, Мөхәммәд расүл Аллаһ" - дип шаһәдәт бирү; Намазны торгызу; Зәкәт бирү; Ураза тоту; Хаҗ кылу".*

Укытучы балаларга Ислам нигезе турындагы хәдиснең гарәпчәсен дә, татарчасын да кабатлатып-кабатлатып ятлата

# Беренче: Лә иләһә иллә Аллаһ




*Балалар! Мин сезгә тарихтан бер вакыйга сөйлим:*

Гали бин Әбий Талиб пәйгамбәребезнең йортында яшәүче сабый иде. Көннәрнең берендә ул өйгә кергәч, пәйгамбәребез хатыны Хәдиҗә белән намаз укыганнарын күрде. Ул намазны белми иде әле. Алар намазларын укып бетергәч, Гали пәйгамбәребездән нәрсә эшләгәннәрен сорады. Пәйгамбәребез аңа, Бердән-Бер Аллаһка намаз укыганнарын әйтте. Шуннан соң, расүлебез аны Исламга чакырды. Гали бераз уйлаганнан соң, *"Әшһәду әллә иләһә иллә Аллаһ, үә әннә Мүхәммәдәр-расүл Аллаһ"*, - дип шәһәдәт кәлимәсен әйтте. Шулай итеп, Гали кечкенә сабыйлардан иң беренче мөселман булды.





Укытучы балаларга кечкенә сахәбәләр тормышларын сөйли, Бер Аллаһка иманның фазыйләтләрен әйтә һәм шәһәдәт кәлимәсен бергәләп кабатлата





Балалар!
Пәйгамбәребез Мәккә
Мөкәрәмәдә "фил"
елында туды. Аның
әтисе Габдуллаһ, ул
туганчы ук инде вафат
булган иде



Кечкенә
Мөхәммәдне
Хәлимә имезеп
ашатты



Пәйгамбәребезгә алты
яшь булганда, аның әнисе
Әминә вафат булды





Пәйгамбәребезнең әнисе
вафат булганнан соң, аны
тәрбиягә бабасы
Габделмотталиб алды



Бабасы Габделмотталиб
та вафат булгач, ул
әтисенең абыйсы Әбү
Талибта тәрбияләнде



Пәйгамбәребез үсте. Әбү
Талиб аны күркәм холыклы
булганы өчен бик тә ярата
торган иде.



Укытучы балаларга кыскача гына пәйгамбәребезнең тормышын сөйли, һәм истә
калсын өчен алдагы дәресләрдә балалардан сорый





Пәйгамбәребез Мәккә әһелләренең сарык көтүләрен көтте



Кешеләр пәйгамбәребезне бик тә яраттылар, һәм аны "тугры-ышанычлы" дип атадылар. Ул шулай ук, сәүдә белән шөгыльләнде. Аның тугры вә ышанычлы булуын кешеләр сокланып искә алалар иде





Пәйгамбәребез Хәдиҗә бинт Хуәйлидка өйләнде



Мөхәммәд пәйгамбәребезгә вахи иңгәнче, ул "Хира" тау куышында гыйбадәт кыла торган иде. Вахи иңгәч ул Аллаһның илчесе булды. Пәйгамбәребез кешеләрне Бер Аллаһка гыйбадәт кылырга чакырды. (Әйт: Ул Аллаһ Бер. Аллаһ һичнәрсәгә мохтаҗ түгел. Ул тудырмады һәм тудырылмады. Һәм Аңа һичкем тиң булмады)





Кешеләр иман китерделәр, һәм Ислам дине барча тарафларга таралды

# Азан вакыйгасы



Мәдинә Мөнәвәрә шәһәрендә мөселманнар бик тә күбәеп киткәч, пәйгамбәребез аларны мәчеткә биш вакыт намазга чакыру юлын уйлый башлады. Берәү: "Намаз вакыты җиткәнен белгертеп байрак күтәрик", - диде. Икенчесе: "Быргы кулланыйк", - диде. Өченчесе: "Чаң кагыйк яки кыңгырау шалтыратыйк", - диде. Пәйгамбәребезгә берсе дә ошамады. Икенче көнне иртә белән Габдуллаһ бин Зәйд пәйгамбәребезгә үзенең бик тә сәер төш күрүен әйтте, һәм сөйләп бирде: "Мин төшемдә ямь-яшелдән киенгән һәм кулына кыңгырау тоткан бер ир-атны күрдем. Мин аннан: "Миңа бу кыңгырауыңны сатмыйсыңмы", - дип сорадым. Ул миңа: "Сиңа нәрсәгә ул?", - диде. Мин аңа: "Без аның белән кешеләрне намазга чакырырбыз", - дип җавап бирдем. Бу ямь-яшел киемле кеше миңа болай диде: "Мин сиңа моннан да яхшыракны өйрәтәм. Син намазга чакырганда болай дип әйт:






Аллаhу әкбәр    Аллаhу әкбәр
Аллаhу әкбәр    Аллаhу әкбәр
Әшhәду әллә иләhә илләАллаh
Әшhәду әллә иләhә илләАллаh
Әшhәду әннә Мухәммәдәр-расулуллаh
Әшhәду әннә Мухәммәдәр-расулуллаh
Хәййә галәс-саләh
Хәййә галәс-саләh
Хәййә галәл фәләх
Хәййә галәл фәләх
Аллаhу әкбәр    Аллаhу әкбәр
Лә иләhә илләАллаh

Пәйгамбәребез бу төшне ишеткәч Габдуллаh бин Зәйдкә: "Дөреслектә бу төш Аллаhтан, иншәАллаh", - диде. Һәм азан әйтер өчен, аңа бу сүзләрне Билалгә өйрәтергә кушты


# Намаз вакытлары



*Мин биш вакыт намазны белән*




*Иртәнге намаз*




*Өйлә намазы*



*Икенде намазы*



*Ахшам намазы*



*Ясту намазы*

# Таһәрат



*Мин таһәрат алам*



*Битне өч тапкыр юам*



*Кулларны терсәккә кадәр өч тапкыр юам*



*Башка мәсех кылам*



*Аякларны тубыкка кадәр өч тапкыр юам*



Укытучы балаларга таһәрат алу тәртибен өйрәтә. Бу сурәттә фарызлар гына күрсәтелгән булса да, ул аларга сөннәтләрен дә аңлатып китә

# Таһәрат догасы

*Таһәрат алганнан соң ошбу доганы укыйм:*

*Әшһәдү әллә иләһә илләАллаһ, үәхдәһү лә шәрикә ләһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ. Аллаһүммәҗгални минәт-тәүүәбин үәҗгални минәл-мүтәтаһһирин*

*«Шаһитлык кылам – хакыйкатьтә, Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Шаһитлык кылам – хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы вә расүле. Әй Аллаһ! Мине күп тәүбә кылучылардан һәм пакьланучылардан кыл»*





Укытучы балаларга таһәрат алганнан соң укыла торган доганы ятлаганчыларына кадәр кабатлата

# Мәчеткә барабыз



Әтием өйрәткән мәчет әдәпләрен онытмыйм:

Мәчеткә уң аяк белән атлап керәм,
һәм болай дип әйтәм: Бисмилләһ,
үәссәләмү галә расүлилләһ,
Аллаһүммәгъфир ли зүнүби үәфтәх
ли әбүәбә рахмәтик «Аллаһ исеме
белән, Аллаһның расүленә сәлам. Әй
Аллаһ! Минем гөнаһларымны ярлыка
һәм миңа Үзеңнең рәхмәт
ишекләреңне ач»



Намаз укучылар
алдыннан узмыйм

Мәчеттә
тыйнаклыкны һәм
пакьлекне саклыйм

Мәчеттән сул аяк
белән чыгам, һәм
болай дип әйтәм:
Бисмилләһ, үәссәләмү
галә расүлилләһ,
Аллаһүммәгъфир ли
зүнүби үәфтәх ли
әбүәбә фәдълик
«Аллаһ исеме белән,
Аллаһның расүленә
сәлам. Әй Аллаһ!
Минем гөнаһларымны
ярлыка һәм миңа
Үзеңнең фазыйләт
ишекләреңне ач»

# Намаз укыйм



*Кыйблага юнәләм һәм:* *"Аллаһу әкбәр"* *- дип әйтәм*



*Фатихә сурәсен һәм бер кыска сурә укыйм*



*Рукугька китәм, һәм өч тапкыр:* *"Субхәнә раббиәл газыйм"* *- дип әйтәм*



*Рукугьтән торам, һәм:* *"Раббәнә ләкәл хәмд"* *- дип әйтәм*



*Сәҗдәгә китәм, һәм өч тапкыр:* *"Субхәнә раббиәл әгьлә"* *- дип әйтәм*



*Сәҗдәдән соң утырам*



Укытучы балаларны намаз тәртибенә өйрәтә, һәм аларның алдында намаздагы хәрәкәтләрне ясап күрсәтә



*Икенче ракәгатькә торып басам, һәм Фәтихә сурәсе белән бер кыска сурә укыганнан соң, рукугь вә сәҗдә кылам*



*Икенче тапкыр сәҗдәгә китәм, һәм өч мәртәбә: "Субхәнә раббиәл әгълә" - дип әйтәм*



*Тәшәһһудне укыйм*



*Уң тарафка борылып: "Әссәләму гәләйкм уә рахмәтуллаһ" - димен, һәм сул тарафка да борылып: "Әссәләму гәләйкум уә рахмәтуллаһ" - димен*



*Намаздан соң ошбу зикерләр укыла:*

* 3 тапкыр "Әстәгъфируллаһ" - димен
* 33 тапкыр "СубхәнАллаһ" - димен
* 33 тапкыр "Әлхәмдулилләһ" - димен
* 33 тапкыр "Аллаһу әкбәръ" - димен
* Ошбу доганы укыйм: "Аллаһуммә әгыйнни галә зикрикә уә шукрикә уә хусни гыйбәдәтик"



Укытучы балалардан намаз тәртибен һәм намаздан соң укыла торган зикер вә догаларны ятлатып сорый. Шулай ук, аларны намазны вакытында укып барырга нәсыйхәт кыла

# Зәкәт

Өченче нигез

Әйдә әле улым Әхмәд, фәкыйрьләргә үзебезнең байлыгыбыздан тиешле хакларын бирик!




Безнең байлыгыбызда фәкыйрьләрнең хаклары бармени әти?



Әйе, улым. Шулай ук, садәка байлыкны пакьли һәм арттыра. Бу хакта сиңа бер хикәя сөйлим:





«Бервакыт берәү сахра буйлап барганда, кинәт болыттан килгән: «Фәләннең бакчасын сугар!» — дигән бер тавыш ишетте, шуннан соң болыт икенче тарафка юнәлде һәм кара ташлы җиргә яңгыр яудырды.Бөтен су бер ташкын булып акты, ә юлчы аның агымы буйлап китте. Ул бакчасында басып торган һәм суны көрәге белән кирәкле якка юнәлтеп торган бер кешене күрде. Аңардан: «Әй Аллаһның колы, синең исемең ничек?» — дип сорады. Ул: «Фәлән», — дип җавап бирде. Болыттан килгән тавыш нәкъ менә бу исемне атаган булып чыкты. Бу кеше юлчыдан: «Әй Аллаһның колы, ни өчен син минем исемемне сорадың?» — диде.

Юлчы: «Дөреслектә, мин бу яңгыр яуган болытлардан: «Фәләннең бакчасын сугар!» — дигән тавыш ишеттем. Ул синең исемең иде. Яңгыр яуырлык, син бу бакча белән нәрсә эшлисең соң?» — диде. Ул: «Син миңа боларны әйткәч, инде мин сиңа җавап бирим: Дөреслектә, уңыш җыйгач мин аның өчтән берен фәкыйрьләргә бирәм, бер өлешен үземә һәм гаиләмә калдырам, ә бер өлешен кире кайтарам» — диде.

# Мин ярдәм итәм

Буя



# Ураза

**Дүртенче нигез**



*Әйдәгез әле балалар, Рамазанның яңа туган аен карыйк бергәләп!*

*Рамазан аенда мөселман кешесе таң атканнан алып кояш баеганчыга кадәр ураза тота*





## Бәйрәм бүген!

Бар күңеллелек бөтен
дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? — Мин беләм:
бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Бөр мөкаддәс хис белән
һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем
бәйрәм көен, бәйрәм бүген!
Арттыра, күрдем, кояш
гадәттәгедән балкуын;
Ул киенгәндер, дидем:
бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Хис итеп һәр җирдә дә
бертөрле хуш ис аңкуын:
Ислемай сөрткән икән дөнья!
дидем: бәйрәм бүген!
Бер теләнчене кочаклашкан
күреп бер бай белән:
Күңле нечкәргән! дидем:
бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Яр башыннан тыңладым мин
бер суның дулкыннарын:
Сөйләшәләр үзара: бәйрәм
бүген, бәйрәм бүген!
Тыңладым әкрен генә
искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын:
бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

(Габдуллаһ Тукай)



# Хаж

Бишенче нигез






Бабам, әйт әле! Кәгьбәтуллаһны кем төзеде



Бу хакта мин сиңа аның тарихын сөйлим, улым:

Кешеләр хаҗ кылсын өчен, Аллаһ тәгалә Ибраһим һәм аның улы Исмәгыйль пәйгамбәрләргә Мәккәдә Кәгьбәтуллаһны төзергә боерды. Ибраһим Аллаһның әмерен үтәргә ашыгып Кәгьбәтуллаһны төзи башлады, ә улы Ибраһим ташлар алып килеп, әтисенә ярдәм итте. Шулай итеп алар төзеп бетерделәр. Аннары, Аллаһ тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә кешеләрне хаҗга чакырырга әмер итте. Бу чакыруны ишетеп, кешеләр барча тарафлардан Мәккәгә хаҗга юнәлделәр




# Ләббәйкә Аллаһүммә ләббәйк

Ибраһим белән Исмәгыйль кешеләргә хаҗ гамәлләрен, һәм Кәгъбәтуллаһ буйлап:

Ләббәйкә Аллаһумммә ләббәйк,
Ләббәйкә лә шәрикә ләкә ләббәйк,
Иннәл-хәмдә үән-нигъмәтә ләкә үәл-мулк,
Лә шәрикә ләк, -

дип таваф кылуны өйрәттеләр



# Корбан гаете



Әйдәгез әле балалар, Аллаһ ризалыгы өчен корбан чалыйк!



Ни өчен эти һәр ел гает намазыннан соң мөселманнар корбан чала?



Бу хакта мин сезгә аның тарихын сөйлим:



## БӨЕК КОРБАН

Ибраһим пәйгамбәр улы Исмәгыйльне бик тә нык ярата иде. Аллаһ тәгалә Ибраһимны сынарга теләп, аңа төшендә улы Исмәгыйльне Корбан итүе белән боерды. Пәйгамбәрләрнең төшләре – хак. Ибраһим Исмәгыйльгә төшен сөйләде, ул этисенә: "Аллаһ сиңа ни боерган булса, шулай эшлә!" – дип, үзенең буйсынганлыгын белдерде.

Ибраһим Исмәгыйльне Корбан итәргә теләп, пычагын күтәрде, ләкин шул вакыт: "Әй Ибраһим! Син төшеңә, боерыгыбызга тугры булдың! Исмәгыйльне калдыр" – дигән тавыш ишетте. Аллаһ Исмәгыйль урынына сарык суярга кирәклеген белдерде. Ибраһим бик шатланып Аллаһка шөкераналар кылды, һәм Корбанга сарык чалды. Шушы көннән алып барча мөселманнар да Аллаһка шөкер йөзеннән Корбан чала торган булдылар, һәм ул ит белән фәкыйрьләрне, туганнарын, дус-ишләрен сыйлыйлар

# Кайбер әдәпләр






Кием салганда:
"Бисмилләһ" - дип әйтәм

Кием кигәндә: "Аллаһуммә ләкәлхәмд! Әнтә кәсәутәниһи әс'әлукә хайраһу уә хайрә мә сунига ләһу, уә әгузу бикә мин шәрриһи уә шәрри мә сунига ләһу"
«Әй Аллаһ, Сиңа барча мактау! Син мине киендердең. Синнән бу киемнең яхшылыгын вә аның нәрсә өчен эшләнгәненең яхшылыгын сорыйм, һәм Сиңа аның явызлыгыннан вә аның нәрсә өчен эшләнгәненең явызлыгыннан сыенам» - дип әйтәм



Пәйгамбәребезнең догаларыннан:
"Аллаһуммә әхсәнтә халкый, фә'әхсин хулукый"
«Әй Аллаһ! Син мине күркәм итеп халикъ кылдың, шулай ук минем холкымны күркәм кыл!»

# Аллаһка тәвәккәллим





Пәйгамбәребез вакытында бер кеше бар иде. Ул Исламны кабул иткәч, мөселман Аллаһка тәвәккәл кылучы икәнлеген аңлады. Көннәрнең берендә ул дөясенә утырды да, пәйгамбәребезне тыңларга дип мәчеткә юнәлде.

Бу кешенең Исламга кадәр, әгәр дә дөясен калдырырга теләсә башта бәйләп куя торган гадәте бар иде.

Мәчеткә килеп җиткәч, ул дөясен бәйләп тормыйча гына: "Аллаһка тәвәккәлләдем" - диде. Пәйгамбәребез аны күреп: "Син башта аны бәйлә, аннары тәвәккәллә!" - диде.

Ягъни, нәрсә эшләсәң дә башта сәбәбен кыл, аннары тәвәккәллә диган мәгънәдә

# Гамәл кылу



*Балалар! Мин сезгә бик матур бер хикәя сөйлим:*

Бервакыт пәйгамбәребез кайбер сахәбәләре белән сәфәргә чыкты. Күпмедер юл узганнан соң, алар сарык суеп ашарга булдылар.

- Берсе: Мин суям - диде.
- Икенчесе: Мин туныйм-эшкәртәм - диде.
- Өченчесе: Мин пешерәм - диде.
- Пәйгамбәребез: Мин утын җыям - диде.
- Сахәбәләр расүлебезгә: Без барысын да үзебез эшлибез әй Аллаһның илчесе! - диделәр.
- Пәйгамбәребез аларга: Мин беләм, ләкин мин сездән аерылырга яратмыйм - диде.

Аннары ул аларга Аллаһ тәгалә гамәл кылучы колын яратканлыгы хакында бәян итте.

Шулай булгач, балалар! Без дә өйдә әти-әниләребезгә ярдәм итик!





# Кайбер әдәпләр



Мөселман төчкергәндә:
Әлхәмдулилләһ - ди
Янындагысы аңа: ЙәрхәмукАллаһ - ди
Беренчесе: Йәхдикумуллаһ үә йүсълих бәләкүм - дип җавап бирә




Мөселман авызын ачып иснәгәндә, аны кулы белән каплый. Чөнки капламаса шәйтан керә



Мөселман өйдән чыкканда:
Бисмилләһ, тәүәккәлтү гәлАллаһ, үә лә хәүлә үә лә куүәтә иллә билләһ - дип әйтә



Мөселман мәчеткә барганда:
Аллаһуммәҗгал фи калби нүран...
- дигән доганы укый


Киләсе
очрашуларга
кадәр:
Әссәләмү
гәләйкүм үә
рахмәтуллаһи
үә бәракәтүһ